2006 ел, 1 март 87

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре” турында 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре” турында 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасын расларга;

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасы көчен югалткан дип танырга;

карарның 2 нче пунктындагы 2 нче абзацында “832,2” санын “846,6” санына үзгәртеп язарга;

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турында нигезләмәгә:

1.2 нче пунктта “шулай ук архитектура һәм шәһәр төзелешенең, торак-коммуналь хуҗалыкның территориаль органнары” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

1.6 нчы пунктны түбәндәгечә язарга:

“1.6. Министрлыкның урыны (юридик адресы): 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 10 нчы йорт”;

3.3.1 нче пунктта:

2 нче абзацта “коммуналь комплекс оешмаларын тариф көйләвендә,” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

5 нче абзацны түбәндәгечә язарга:

“Билгеләнгән тәртиптә, учреждение, дәүләт предприятиеләре һәм башка оешмалар эшчәнлеген һәм дәүләт мөлкәтен файдалануны тикшерүне гамәлгә ашыра;”;

10 нчы абзацта “республика” дигән сүздән соң “һәм ведомство буйсынуындагы” дип өстәргә;

14 нче абзацта “дәүләт унитар предприятиеләре һәм учреждениеләре балансындагы” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

18 нче абзацны түбәндәгечә язарга:

“үз илебез һәм чит ил инвесторлары өчен, аларны төзелеш материаллары сәнәгатендә, төзелеш индустриясе һәм торак-коммуналь комплексында, төзелеш һәм торак, коммуналь инфраструктураны үстерү өчен югары сыйфатлы продукция җитештерүне оештыруда аларны җәлеп итү өчен уңай шартлар тудыра;”;

20 нче абзацта “дәүләт милкендә булган” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

10-23 нче абзацларны шул ук эзлеклелектә 11-21, 23, 24, 25 нче абзацлар дип санарга;

3.3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“алып бару өлкәсендә билгеләнгән ведомствога караган максатчан программалар эшли һәм гамәлгә ашыра;”;

3.3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 22 нче абзац өстәргә:

“әзерлекне, җирле бюджетлар тарафыннан муниципаль үсеш фондыннан, социаль чыгымнарны финанслашуның төбәк фондыннан субсидияләрне файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары турында муниципаль районнар, шәһәр округлары белән килешүләр төзүне тәэмин итә;”;

3.3.2 нче пунктта:

3 нче абзацны түбәндәгечә язарга:

“билгеләнгән тәртиптә, территориаль планлаштыру документлары проектларын һәм проектлау документларын дәүләт экспертизасы үткәрүне оештыра һәм законнар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабыннан төзелә торган төзелеш объектларына проектлау-смета документларын раслый”;

4 нче абзацта “әгәр төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонт ясаганда законнарда дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру каралган булса,” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

5 һәм 6 нчы абзацларда “әзерләүдә катнашалар” дигән сүзләрне “әзерләүне тәэмин итәләр” дип үзгәртеп язарга;

9 абзацта “җөмләне” дигән сүзне “җөмләләрне” дип үзгәртеп язарга;

3.3.3 пунктында:

7 абзацта “Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

10 нчы абзацны түбәндәгечә язарга:

“Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән берлектә, торак-коммуналь комплекс тармагы буенча бюджетны оештырганда, билгеләнгән өлкәдә бюджетара трансфертлар (субсидия һәм субвенцияләр) бирү ихтыяҗын хисаплаганда катнаша;”;

12 нче абзацны түбәндәгечә язарга:

“торак бүлмә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә халыкка социаль ярдәм чараларын камилләштерүдә катнаша;”;

10-13 нче абзацларны шул ук эзлеклелектә 11-14 нче абзацлар дип санарга;

3.3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 10 нчы абзац өстәргә:

“торак-коммуналь комплекс оешмаларының җитештерү, инвестиция һәм инновация эшчәнлеген индикатив бәяләүне гамәлгә ашыра;”;

3.3.4 нче пунктта:

4-11 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“төбәк стандартларының халыкның яшәү дәрәҗәсенең чынбарлыктагы күрсәткечләренә, торак-коммуналь хезмәтләр бәяләренә, халыкның торак мәйдан белән тәэмин итүчәнлегенә туры килү мониторингы күрсәткечләрен җыю һәм анализлаулы гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына торак һәм коммуналь хезмәтләргә түләүнең төбәк стандартлары күләмен вакытыннан алда кабат карап чыгу тәкъдимнәрен кертә;

федераль законнарда күрсәтелгән очракларда су белән тәэмин итү, файдаланылган суны агызу һәм агымты суларны чистарту, каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү (күмү) тарифларын дәүләт көйләвен гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре буенча коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәтләренә тарифларга өстәмәләрне исәпкә алып, коммуналь комплекс оешмалары товарлары һәм хезмәтләренең билгеләнгән тарифларын үзгәртүнең максималь мөмкинлегенең соңгы чик индексларын билгели;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре буенча коммуналь хезмәтләр күрсәтү чыгымнары, торакны карап тоту һәм ремонтлау чыгымнары, торак-бүлмә һәм коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләү нисбәтен исәпкә алып, коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртүнең соңгы чик индексы һәм торак-бүлмә өчен гражданнар түләвенең үзгәртүнең соңгы чик индексын билгели;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр күзлегеннән торак-коммуналь хезмәтләр җыелмасы бәясенең соңгы чик әһәмиятен эшли;

күрсәтелгән бәяләрне формалаштыру шартларын бозган очракта, торак-коммуналь комплекс оешмалары хезмәтенә көйләүле бәяләр булдыручы субъектлар мәнфәгатьләрен яклауның икътисадый механизмын тәэмин итә;

торак-коммуналь хезмәтләр җыелмасы бәясенең соңгы чик әһәмиятләренә көйләүле бәяләрнең туры килүен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;”;

12 нче абзацны төшереп калдырырга;

4.1 нче пунктның 2нче абзацында “учреждениеләр тарафыннан” дигән сүзләрне “оешмалар тарафыннан” дип үзгәртеп язарга;

4.2 нче пунктны төшереп калдырырга;

4.3-4.5 нче пунктларны шул ук эзлеклелектә 4.2-4.4 нче пунктлар дип санарга;

5.3 нче пунктның 7 абзацында “һәм аның территориаль органнары” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә “Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы предприятиеләр, учреждение һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итә торган икътисадый эшчәнлек төрләре исемлеге” дигән кушымтага түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | |
|---|---|
| “40 | Электр энергиясе, газ, пар һәм кайнар су җитештерү, тапшыру һәм бүлү |
| 40.3 | Пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) җитештерү, тапшыру һәм бүлү |
| 40.30 | Пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) җитештерү, тапшыру һәм бүлү |
| 40.30.14 | Пар казаннарының пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) җитештерү |
| 40.30.2 | Пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) тапшыру |
| 40.30.3 | Пар һәм кайнар суны (җылылык энергиясен) бүлү |
| 40.30.4 | Пар казаннарының эшләү мөмкинлеген тәэмин итү эшчәнлеге |
| 40.30.5 | Җылылык челтәрләренең эшләү мөмкинлеген тәэмин итү эшчәнлеге |
| 70.32.2 | Торак булмаган фондны файдалану белән идарә итү |
| 91.3 | Башка иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеге”. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры Р.Н.Миңнеханов

F:\KARAR\3581603з2.doc